ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 июля 2017 г. № 4318

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль ярдәм күрсәтү хокукын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М :

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 номерлы, 2017 елның 14 апрелендәге 2234 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) II. «Бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү» бүлегендә:

1 пунктның «2017 ел (мең сум)» графасында «112,0» цифрын «106,0» цифрына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлының «2017 ел (мең сум)» графасында «890,0» цифрын «884,0» цифрына алмаштырырга;

2) IV. «Балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру» бүлегендә:

1 пунктның «2017 ел (мең сум)» графасында «1000,0» цифрын «1006,0» цифрына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлының «2017 ел (мең сум)» графасында «1852,0» цифрын «1858,0» цифрына алмаштырырга;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин